Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи жирлеге башкарма комитеты карары

2014 елның 14 апреле 12№

Җәмәгать тыңлауларны үткәрү урынында территорияне (бинаны) тутыруның чик нормаларын билгеләү турында.

2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасында митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар җыелышларын уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашучы гражданнарның, ачык чаралар үткәрү өчен файдаланыла торган объект һәм биналарның иминлеген тәэмин итү, шулай ук җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашмаучы затларның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны булдырмау максатларында карар бирәм:

1. Түбән Кәчи жирлеге жирле үзидарә органнарына җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәрнамә бирелгәндә чара үткәрү урынында территориянең( бина) тулыландырылуының түбәндәге нормаларын билгеләргә:

   - стационар тамашачы урыны белән жиһазландырылган бинаның иң чик тыгызлыгы - 200 стационар тамашачы урыны, Ташбилге авылы.

   - стационар тамашачы урыны белән жиһазланмаган бинаның иң чик тутырылышы җәмәгать тыңлаулары чарасы үткәрелгән урында 1 квадрат метрга бер кешедән артмый, яки бинаның (корылманың) техник паспорты нигезендә,

   - тротуар, административ биналар янындагы мәйдан һәм мәдәни-күңел ачу учрежденияләрендә - 1 квадрат метрга 3 кешедән артмый.

2. Әлеге карарны Түбән Кәчи жирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Түбән Кәчи жирлеге
Башкарма комитеты житәкчесе: М.И.Елифанов